ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга (алга таба – ятим балалар) милек хокукында туры килүче, ятим балаларга «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясында каралган торак урыннар белән тәэмин итү хокукын гамәлгә ашыру тәртибендә бирелгән торак йортлар яисә блоклы төзелгән йортлар урнашкан җир кишәрлекләре ятим балаларга милеккә түләүсез бирелә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $32^2$ статья өстәргә:

«$32^2$ статья. **Җир кишәрлекләрен ятим балаларга милеккә түләүсез бирү тәртибе**

1. Әлеге Кодексның 32 статьясындагы 8 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү мондый җир кишәрлеге белән эш итү хокукына ия башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Бирелә торган җир кишәрлегенең күләме Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында мондый җир кишәрлеге мәйданы турында белешмәләр нигезендә билгеләнә.

3. Җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү турында яисә бирүдән баш тарту хакында карар башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{14}$ – $39^{17}$ статьялары нигезендә кабул ителә.

4. Башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{14}$ статьясында каралган тәртиптә җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән гражданның (алга таба – гариза бирүче) аңа җир кишәрлеген милеккә түләүсез бирү хокукын раслаучы түбәндәге документларны соратып ала:

1) сорала торган җир кишәрлегенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне;

2) сорала торган җир кишәрлегендә урнашкан торак йортка яисә блоклы төзелгән йортка Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне;

3) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы вәкаләтле органының гариза бирүчегә махсуслаштырылган торак урынына наем шартнамәсе буенча «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясында каралган торак урыннар белән тәэмин итү хокукын гамәлгә ашыру тәртибендә торак йорт яисә блоклы төзелгән йорт бирү турындагы карарын;

4) әлеге пунктның 3 пунктчасында күрсәтелгән торак йортны яисә блоклы төзелгән йортны гариза бирүчегә милеккә тапшыру турында килешү.

5. Әлеге статьяның 4 пунктында күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан аның үз теләге белән тапшырылырга мөмкин.

6. Әгәр торак йорт яисә блоклы төзелгән йорт гариза бирүченең, иренең (хатынының) һәм (яисә) балаларының өлешле гомуми милкендә булса, аларга җир кишәрлеге торак йортка яисә блоклы төзелгән йортка милек хокукындагы өлешкә пропорциональ рәвештә өлешле гомуми милеккә түләүсез бирелә.

7. Әлеге статьяның 6 пунктында күрсәтелгән очракта башкарма хакимиятнең вәкаләтле органына яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органына өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла:

1) өлешле милектә һәр катнашучыдан җир кишәрлеге бирү турында гариза;

2) өлешле милектә һәр катнашучының шәхесен таныклаучы документлар;

3) өлешле милектә катнашучы вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ (вәкил мөрәҗәгать иткән очракта).».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 53-ТРЗ